# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Октябрь-Буләк авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**06 декабрь 2021 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 06 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Буләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Октябрь-Буләк авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Октябрь-Буләк авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Октябрь-Буләк авылы, Үзәк урамна инвентарь сатып алу;
- Октябрь-Буләк авылында зират территориясен киртәләү өчен материаллар (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 79 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 48.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 48, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Буләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип танырга.
2. Түбәнәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Булэк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Октябрь-Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Октябрь-Бүләк авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Октябрь-Бүләк авылы, Үзәк урамна инвентарь сатып алу;
- Октябрь-Бүләк авылында зират территориясен киртәләү өчен материаллар (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге башлыгы — А.Р. Ногманов

КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ